| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2025 Девәтернә авылы № 4-1

Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 54-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Бюджет кодексы нигезендә, 2025 елның 21 апрелендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең закон актлары аерым нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең закон актлары аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыгуын тану һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында Федераль законының 14 һәм 15 нче маддәләренә үзгәрешләр кертелү турында” 84-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 2025 елның 23 октябрендәге 02-08-01-2025/157 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 54-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Девәтернә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 30 нчы маддәнең 5 нче өлешендә «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре» сүзләреннән соң «(публичный партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 42 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге тугызынчы пункт белән тулыландырырга:

«9. Агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирүне таләп итә торган суд актларын үтәү (кешеләргә китерелгән зыянны компенсацияләү максатыннан чыгарылган суд актларыннан тыш), суд актында билгеләнгән максатларга туры килгән чыгым статьялары буенча

бюджет турындагы закон (карар) белән каралган ассигнованиеләр чикләрендә башкарыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Э.Э. Ганиев

Совет Девятерчинского сельского поселения
Девәтернә авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002646